**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ГЛАВА**
**Старосляковского сельского поселения**
**Агрызского муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Әгерҗе муниципаль районы**
**Иске Эсләк авыл җирлеге**
**БАШЛЫГЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

18.11.2019 Үтәгән авылы № 4

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Иске Эсләк авыл җирлеге Үтәгән авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьялары, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Иске Эсләк авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Иске Эсләк авыл җирлеге башлыгы к а р а р б и р д е:

1. Үтәгән авыл клубы бинасында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2019 елның 30 ноябрендә 15 сәгать 00 минутта билгеләргә.

2.Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге сорауны расларга: « Иске Эсләк авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча Үтәгән авылында теркәлгән һәр балигъ булган кешедән ,I төркем инвалидларыннан, көндезге формада белем алучы студентлардан, Россия Армиясендә хезмәт итүче һәм иректән мәхрүм итү урыннарында булган затлардан тыш , 2020 елда узара салым акчасын 400 сум күләмендә кертергә һәм шул акчаларны җирле мәсьәләләрне хәл итәргә юнәлтергә Сез ризамы:

1)Үтәгән авылында Су буе урамына вак таш җәю.

2)Үтәгән авылында суүткәргеч челтәре өчен су насосы сатып алу.

«ӘЙЕ» «ЮК".

3. Иске Эсләк авыл җирлеге Башкарма Комитетына халык җыенын оештыруны һәм уздыруны йөкләргә.

4. Әлеге карарны кабул ителгән көннән соң 5 көн эчендә җирлекнең мәгълүмат стендларында урнаштыру, http://pravo.tatarstan.ru Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында һәм http://agryz.tatarstan.ru Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Әгерҗе муниципаль районы сайтында бастырып чыгару юлы белән халыкка җиткерергә.

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

И.Н. ГАФАРОВ